ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.08.2026 г.Лениногорск № 575

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «2026 елда Лениногорск муниципаль районы бюджетыннан авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә татар токымлы ана атларны карап тотуга бәйле чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2026 елның 19 июнендәге 417 номерлы карары белән расланган 2026 елда Лениногорск муниципаль районы бюджетыннан авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә татар токымлы ана атларны карап тотуга бәйле чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «2026 елда Лениногорск муниципаль районы бюджетыннан авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә татар токымлы ана атларны карап тотуга бәйле чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2026 елның 19 июнендәге 417 номерлы карары белән расланган 2026 елда Лениногорск муниципаль районы бюджетыннан авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә татар токымлы ана атларны карап тотуга бәйле чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Субсидия алучыларга татар токымлы ана атларны тоту белән бәйле чыгымнар өлешен кертү өчен бирелә торган субсидия күләме (W) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W = KJ \times S,$$

биредә:

KJ-агымдагы финанс елында субсидия бирү турында мөрәҗәгать итү датасына субсидия алучының татар токымыннан булган ана аты, баш саны;

S-бер баш татар токымлы атка 11 627 сум 00 тиен исәбеннән субсидия ставкасы, ләкин бер башка исәпләгәндә ана татар токымлы атларны тотуга факттагы чыгымнар суммасыннан артык түгел.

Шул ук вакытта субсидия суммасы субсидия алучының татар токымлы ана атларны асрауга бәйле фактта тотылган чыгымнарыннан артмаска тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында веб-адресы буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Г.А. Ивановага йөкләргә.

Җитәкче И.Г. Шәмәрданов

Нуриева Л.И.
5-25-13